КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 август г.Казань № 665

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән расланган Электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга яки җитештерүгә һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждение-ләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга яки җитештерүгә һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 декабрь, 1402 нче; 2023 ел, 27 апрель, 531 нче; 2023 ел, 13 сентябрь, 1120 нче; 2023 ел, 20 октябрь, 1333 нче; 2023 ел, 15 декабрь, 1614 нче; 2024 ел, 23 май, 358 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Электр автомобиль транспорты тиз

заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга яки җитештерүгә һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның өченче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә:

«Торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан заряд алу инфраструктурасы объектыннан файдалану мөмкинлеге аннан файдаланучылар өчен аена вакытның кимендә 95 проценты булырга тиеш. Заряд алу инфраструктурасы объекты төзек булмаган очракта, эшли башлау сәләтен торгызу вакыты иң күбе 12 сәгать тәшкил итәргә тиеш.»;

2.5 пунктта:

2.5.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.2. Бер заряд алу инфраструктурасы объектын технологик тоташтыруга субсидия күләме ($С_{iтп}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_{iтп} = 0,6 \text{ x } З_{iтп},$$

монда $З_{iтп}$ – субсидия алучының заряд инфраструктурасы объектын электр челтәрләренә (энергия белән тәэмин итү объектына) технологик тоташтыруга фактта тотылган чыгымнары.

Фактта тотылган чыгымнар әлеге Тәртипнең 3.3 пунктындагы 3.3.2 пунктчасының утыз сигезенче абзацында күрсәтелгән документлар белән расланырга тиеш.

Территориаль челтәр оешмасы булган сайлап алуда катнашучы өчен бер заряд алу инфраструктурасы объектын технологик тоташтыруга субсидия күләме ($С_{iтптсо}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_{iтптсо} = 0,6 \text{ x } З_{iтптсо},$$

монда $З_{iтптсо}$ – заряд алу инфраструктурасы объектын технологик тоташтыруга фактта тотылган чыгымнар һәм заряд алу инфраструктурасы объектын электр челтәрләренә технологик тоташтыру өчен стандартлаштырылган тариф ставкаларын кулланып исәпләнгән чыгымнар арасындагы иң аз күләм.

Фактта тотылган чыгымнар әлеге Тәртипнең 3.3 пунктындагы 3.3.2 пунктчасының кырык беренче – кырык алтынчы абзацларында күрсәтелгән документлар белән расланырга тиеш.

Технологик тоташтыруга субсидия бер заряд алу инфраструктурасы объектына иң күбе 900 мең сум күләмендә бирелә.»;

2.5.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.3. Бер заряд алу инфраструктурасы объектына ($С_i$) субсидиянең гомуми күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_i = С_{iобор} + С_{iтп}.$$

Территория челтәре оешмасы булган сайлап алуда катнашучы өчен бер заряд алу инфраструктурасы объектына субсидия күләме ($C_{iтсо}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{iтсо} = C_{iобор} + C_{iтптсо}.»;$$

3.2 пунктның җиденче абзацына «җир кишәрлегендә» сүзләреннән соң «яисә аның белән чиктәш җир кишәрлегендә» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктның 3.3.2 пунктчасында:

егерме беренче абзацта «акт күчермәсен» сүзләреннән соң «яки челтәр оешмасы тарафыннан электр челтәрләренә тоташтыру мөмкинлеге тәэмин ителү турында хәбәрнамә күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

егерме икенче абзацта «шартнамә күчермәсен» сүзләреннән соң «яки заряд алу инфраструктурасы объектын урнаштыру өчен 2015 елның 1 гыйнварыннан соң электр челтәрләренә тиешле рәвештә тоташтырылган капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан җир кишәрлеген арендага бирү турында булган, сайлап алуда катнашучы һәм капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан әлеге җир кишәрлеге милекчесе арасында төзелә торган шартнамә күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

егерме сигезенче абзацта «акт күчермәсен» сүзләреннән соң «яки челтәр оешмасы тарафыннан электр челтәрләренә тоташтыру мөмкинлеге тәэмин ителү турында хәбәрнамә күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

егерме тугызынчы абзацта «шартнамә күчермәсен» сүзләреннән соң «яки заряд алу инфраструктурасы объектын урнаштыру өчен 2015 елның 1 гыйнварыннан соң электр челтәрләренә тиешле рәвештә тоташтырылган капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан җир кишәрлеген арендага бирү турында булган, сайлап алуда катнашучы һәм капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан әлеге җир кишәрлеге милекчесе арасында төзелә торган шартнамә күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

утыз алтынчы абзацта «акт күчермәсен» сүзләреннән соң «яки челтәр оешмасы тарафыннан электр челтәрләренә тоташтыру мөмкинлеге тәэмин ителү турында хәбәрнамә күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

утыз җиденче абзацта «шартнамә күчермәсен» сүзләреннән соң «яки заряд алу инфраструктурасы объектын урнаштыру өчен 2015 елның 1 гыйнварыннан соң электр челтәрләренә тиешле рәвештә тоташтырылган капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан җир кишәрлеген арендага бирү турында булган, сайлап алуда катнашучы һәм капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан әлеге җир кишәрлеге милекчесе арасында төзелә торган шартнамә күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

кырыгынчы абзацта «шартнамә күчермәсен» сүзләреннән соң «яки заряд алу инфраструктурасы объектын урнаштыру өчен 2015 елның 1 гыйнварыннан соң электр челтәрләренә тиешле рәвештә тоташтырылган капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан җир кишәрлеген арендага бирү турында булган, сайлап алуда катнашучы һәм капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары

урнашкан әлеге җир кишәрлеге милекчесе арасында төзелә торган шартнамә күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Заряд алу инфраструктурасы объектын урнаштыру өчен 2015 елның 1 гыйнварыннан соң электр челтәрләренә тиешле рәвештә тоташтырылган капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан җир кишәрлеген арендага бирү турында булган, сайлап алуда катнашучы һәм капиталь төзелеш объектлары яки юл сервисы объектлары урнашкан әлеге җир кишәрлеге милекчесе арасында төзелә торган шартнамә күчермәсе заряд алу инфраструктурасы объекты түбәндәге урыннарда төзегәндә әлеге пунктчаның егерме икенче, егерме тугызынчы, утыз җиденче, кырыгынчы абзацлары нигезендә документлар исемлегенә кертелә:

үз составында ким дигәндә җәмәгать туклануының стационар ноктасы һәм бәдрәфе булган капиталь төзелеш объекты урнашкан җир кишәрлегендә;

үз составында ким дигәндә җәмәгать туклануының стационар ноктасы һәм бәдрәфе булган юл сервисы объектының җир кишәрлегендә, гомуми файдаланудагы федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлында.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заряд алу инфраструктурасы объектын үз челтәрләренә подряд оешмалары катнашыннан башка технологик тоташтыруны гамәлгә ашырганда, әлеге пунктчаның кырык икенче – кырык дүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар әлеге пунктча нигезендә сайлап алуда катнашучы тарафыннан урнаштырыла торган документлар исемлегенә кертелми.»;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның унөченче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә:

«Торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан заряд алу инфраструктурасы объектыннан файдалану мөмкинлеге аннан файдаланучы өчен аена вакытның кимендә 95 процентын тәшкил итә. Заряд алу инфраструктурасы объекты төзек булмаган очракта, эшли башлау сәләтен торгызу вакыты иң күбе 12 сәгать тәшкил итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин